ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.10.2024. с.Старое Дрожжаное № 448

Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча Бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 21 сентябрендәге 820 номерлы карары нигезендә «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча Бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 30 мартындагы 151 номерлы ( 24.01.2022 № 42, 30.01.2024 № 36, 13.06.2024 № 260 редакциясендә) «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча Бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турында»гы карары белән билгеләнгән Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча Бердәм тариф сеткасы таратылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен 2025 елның 1 гыйнварыннан арттырырга.

2. Бу карарның 1 пункты нигезендә Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча Бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләү өчен районда Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча Бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең кайбер оешмасындагы структур бүлекчәсе җитәкчесе секретаренең вазыйфаи оклады күләмен 1,05 тапкырга индексацияләргә һәм аның күләмен 13 990 сум күләмендә билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 30 мартындагы 151 номерлы карарына (24.01.2022 № 42, 30.01.2024 № 36, 13.06.2024 № 260 редакциясендә) үзгәреш кертергә, **1 пунктның дүртенче абзацында** «13 323 сум» сүзләрен «13 990 сум» сүзләренә алмаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru).

6. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Р.И. Мөхәммәтҗанов